ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ДАНАУРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. **№ 56/1**

Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Данауровка авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Данауровка авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 55/1 номерлы карары, Данауровка авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 11 номерлы карары белән, Данауровка муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм күп балалы гаиләләрдән кала, 2019 елда 200 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы:

-урам яктыртуга(яктылык саклаучы урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыруга, искеләрен алмаштыруга),

- Данауровка авылы Үзәк урамына янгын сүндерү гидранты сатып алуга, урнаштыруга;
- Данауровка авылы Пушкин урамы юлына ремонт ясауга, щебенка җәюгә;

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Данауровка авыл җирлеге
башлыгы В.К. Садрутдинова